Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

# ТЫЛСЫМ+

№3 (21) Март-апрель, 2017 нче ел



*26 апрель - татар халкының бөек улы Габдулла Тукай туган көн.*

**Бу санда:**



*“Без—Тукай оныклары” иҗади сәхифәсе махсус кушымтасында гимназия укучылары иҗаты белән таныша аласыз.*

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### “Сердәш” әниләр советы – балаларга



Татарстанның атказанган укытучысы, мәгариф ветераны Роза Нәгыйм кызы Низамова – гимназия әниләре һәм әбиләре советының иң актив әгъзасы. Ул - балаларны милли рухта тәрбия бирү эшендә әйдәп йөрүче тынгысыз зат. Район күләмендә үткәрелгән “Тормыш дәресләре” кысаларында уздырылган чараларда эчтәлекле чыгышлары, төпле акыллы киңәшләре белән ярдәм итә. Быел ул үзенчәлекле яңа төрдәге эшчәнлек белән гимназиянең класстан тыш тормышында матур эз калдырды. Кызлар өчен “Ак калфак” түгәрәге оештырып, бер төркем кызларны милли баш киеме саналган калфак тегү серләренә төшендерде. Р.Низамова һәм укытучы Л.Солтанова белән берлектә укучылар халкыбызның күңел җәүһәрләрен барладылар. Балалар, үз эшләрен бүләк итеп, якыннарын сөендерделәр.

### “Бәллүр бишек” балалар иҗаты фольклор фестивале




“Бәллүр бишек” балалар иҗаты фольклор фестиваленең район этабында беренче урын яулап, гимназиянең музыка укытучысы Гөлнур Әзһәм кызы Фәрхетдинова җитәкчелегендәге “Беләзек” ансамбле төбәк конкурсында катнашу хокукы алды. Ансамбль составында район тамашачылары алдында танылып килгән Резида Сәяхова (скрипка), Назгөл Гайфетдинова (флейта), курайчы егетләр Булат Әхмәтҗанов, Динар Гыйздәтов, баянчы егет Айнур Госманов, Камилә Фәхретдинова, Зилия Әгълиуллина (шакыгычлар), Равилә Шәяхмәтова (мандолина), гитарачы Ранис Тулбаев, Адилә Гыйльметдинова, Әмир Мадьяров, Данияр Кашапов, Алмаз Исламов (кашык) бар. 6 апрельдә Яр Чаллы шәһәрендә уңышлы чыгыш ясап, “Беләзек” фольклор ансамбле фестивальнең беренче дәрәҗә лауреат исеменә лаек булды. Балалар халыкара конкурста катнашу хокукына ия булдылар.

### Театр һәм балалар



Гимназиядә оештырылган “Балкыш” театр түгәрәге сәләтле егетләрне һәм кызларны берләштерде. Сәхнә дәрте белән янучы егетләр-кызлар гимназия кысаларында гына түгел, район, республика күләмендә танылып килүче коллективлар рәтендә йөри. Бу уку елында “Сәйяр” театр конкурсының зона этабында уңышлы чыгыш ясап, “Балкыш” театры коллективы ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Грамотасы белән бүләкләнде. Коллектив “Театр һәм театр” конкурсында Г.Камалның “Беренче театр” әсәрен сәхнәләштереп, “Драматик театр” номинациясендә 3 урынга лаек дип табылды. Җитәкчесе - Ямалова Гөлнара Фердинант кызы.



## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### ИҢ СӘЛӘТЛЕ УКУЧЫЛАР – БЕЗДӘ!



Иң сәләтле укучыларны ачыклау максатыннан, Казан шәһәрендә 9-11 нче сыйныф укучылары арасында математика, физика, химия, инглиз теле буенча республика олимпиадалары үтте. Гимназия укучылары олимпиадаларда зур нәтиҗәләргә ирештеләр. 10 нчы б сыйныфы укучысы Аида Галимова математика фәне буенча, Зөфәр Мөҗипов химия буенча республика призеры булдылар. Дәрәҗәле олимпиадага җиңүчеләрне укытучы Г.Ә.Асылгәрәева һәм В.Г.Семенова әзерләде.

### АК ЮЛ СЕЗГӘ, КЫЗЛАР!

Эльвина Шамукаева һәм Язилә Әгълиуллина татар теленнән Халыкара олимпиадада катнашу хокукына ия булдылар. Укучылар икесе дә татар теле һәм әдәбияты буенча 3 ел рәттән республика олимпиадасы призерлары. Алар фән буенча, Татарстан халкы тарихы буенча белемнәрен сынаячак һәм иҗади конкурсларда катнашачаклар. Америка, Канада, Австралия, Финляндия, Польша, Кытай, Япония, Казахстан һ.б. илләрдән, Россиянең татарлар яшәгән барлык төбәкләреннән җыелган яшьтәшләре белән аралашачаклар. Халыкара олимпиада кысаларында укучылар өчен Казан шәһәренең тарихи-истәлекле урыннарына экскурсия, Тукай-Кырлайга сәяхәт, Г.Камал театрын тамаша кылу, КФУ белән танышу, күренекле галимнәр, язучылар белән очрашулар, мастер-класслар планлаштырыла. Укучылар “Мөслим - туган төбәгем. Туган җирем үсешендә минем өлешем” проектын якларга әзерләнәләр. Кызларыбызның уңышлы чыгыш ясап, җиңүләргә ирешүен телибез.



### БЕЗНЕҢ УКУЧЫЛАР МӘСЬӘЛӘЛӘР ТӨЗИ

Туган төбәккә кагылышлы мәсьәләләр төзүгә багышланган “Татарстан в математических задачах” республика конкурсында 2 нче а сыйныфы укучысы Ралина Хатипова (Л.Г.Мортазина), 6 нчы б сыйныфы укучылары Илһам Бариев, Лиана Хәбибуллина (Л.Н.Заялова) барысы да икенче дәрәҗә дипломга ия булдылар. Аларның хезмәтләре шул исемдәге җыентыкта басылды.



### ТУФАН МИҢНУЛЛИН ИСЕМЕНДӘГЕ КОНФЕРЕНЦИЯ

24 нче мартта Казан шәһәре Фатиха Аитова исемендәге 12 нче кызлар гимназиясендә республикакүләм Туфан Миңнуллин исемендәге республикакүләм конференция узды. 8Б сыйныфы укучылары Ханнанова Алинә икенче дәрәҗәле дипломга, Хаертдинова Алинә лауреат исеменә лаек булды. Кызларның хезмәте хөкемдарлар тарафыннан югары бәяләнде. Фәнни җитәкчесе - Шәнгәрәева Зөлфирә Нәсих кызы.

Гимназиянең башлангыч класслар укытучысы Исмәгыйлова Гөлчәчәк Фирдәвис кызы конференциядә чыгыш ясап, укытучылар арасында икенче урынга лаек булды. Аның эше катнашучылар арасында зур кызыксыну уятты.



### НӘНИЛӘРЕБЕЗ ТАБИГАТЬ САГЫНДА

Кече яшьтәге мәктәп укучыларының төбәкара “Юннат – 2017” экологик фәнни-практик конференциясендә гимназиянең 4 нче б сыйныфы укучысы Илина Бариева җиңүче булды. Фәнни җитәкчесе - биология укытучысы Бариева Л.Ф.

### ТАБИГАТЬ ҺӘМ БЕЗ

“Татарстан Республикасының экологик-географик үзенчәлекләре” төбәкара фәнни-практик конференциясе җиңүчесе – гимназиянең 7 нче в сыйныфы укучысы Аделина Сабитова. Фәнни җитәкчесе – география укытучысы Г.Н.Рәхимуллина.



## IV РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ “ФОАТ САДРИЕВ УКУЛАРЫ – 2017”

***Һәр ел саен җир өстенә язлар килә...***
***Мөслимгә язларны кем алып килә?***
***Фоат Садриев алып килә...***





Болай дип әйтүем март башында Фоат аганың туган көне булган өчен генә түгел. Яз башында мул сулы елгалар ярларыннан тулып ташыган кебек, аның әдәбиятыбызга керткән саллы өлеше өчен; аяусыз нечкә язгы җилләр кебек, дөреслекне күзгә бәреп әйтә белүе, гаделлек өчен көрәшүе; язгы назлы кояш кебек иркәләп, кадерләп, телебез сагында торганы, безнең Мөслим якларына гына хас булган гаҗәеп бай, үзенчәлекле сөйләмебезне бөтен муллыгы белән киләчәк буыннарга тапшыра белүе өчен; үз җиребезне зурлап, безнең белән аралашып, мәгърифәт нуры чәчеп яшәве – чын үз кешебез булганы өчен шулай дип әйтәсе килә.

“Мөслимгә язларны Фоат Садриев алып килә” дип әйтүемнең тагын бер сәбәбе - язлар безгә “Фоат Садриев укулары” фәнни-тикшеренү конференциясен алып килә....

Татарстан Республикасы Язучылар Союзы, “ТАТМЕДИА” ачык акционерлык җәмгыяте филиалы “Мәгариф” журналы редакциясе белән берлектә Мөслимдә дүртенче тапкыр “Фоат Садриев укулары” уздырыла. Быел анда Алабуга, Алексеевск, Актаныш, Әлки, Әлмәт, Балтач, Балык Бистәсе, Бөгелмә, Казан, Кама Тамагы, Мамадыш, Мөслим, Питрәч, Сарман, Түбән Кама, Чирмешән, Яр Чаллы муниципаль районнары укучылары, укытучылары катнашты. Гимназия укучылары Регина Шәйгәрданова (Э.В.Тимергалиева), Зөлфәт Әхмәтҗанов (Г.Ш.Мирзасалихова), Алинә Әхмәтҗанова (Г.М.Мирзамуратова), Азалия Габидуллина (Л.Ә.Фәхертдинова) фәнни-тикшеренү эшләре яклап, беренче урыннарны яуладылар.

Безнең буын – бәхетле буын. Фәнни-тикшеренү конференциясендә катнашучылар Халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе иясе, Мөслимнең шәрәфле гражданины, Р.Төхфәтуллин, С.Сөләйманова бүләкләре иясе – прозаик, драматург, публицист Фоат Садриев белән тере аралашу мөмкинлегенә ия булган бәхетле кешеләр!

Ходай бездән бу бәхетне күпсенмәсен! Җир өстенә килгән язлар белән бергә безгә кабат очрашулар насыйп булсын! Яңа иҗат планнары белән янган Фоат агабыз әдәбият сөючеләрне яңа әсәрләре белән куандырып торсын!

***Регина Шәйгәрданова, 11 нче сыйныф укучысы***







### САННАР НИ СӨЙЛИ?

**Фоат Садриев ул - прозаик, драматург, публицист**

*1981 нче ел - СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы*

*1991 нче ел - «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе»*

*1994 нче ел - «Таң җиле» романы өчен Әлмәт Язучылар берлегенең Р.Төхфәтуллин исемендәге әдәби бүләге иясе*

*«Шаһзаманов эше» китабы өчен Р.Фәхретдинов исемендәге премия иясе*

*2006 нчы ел - С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия иясе*

*2010 нчы ел - “Бәхетсезләр бәхете” роман-трилогиясе өчен Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе*

*2010 нчы ел - Мөслим районының Мактаулы гражданины*

*2010 нчы ел - Мөслимдәге яңа урамга Фоат Садриев исеме бирелде*

*2014 нче ел - Халык язучысы*



## ШАГЫЙРӘ КЛАРА БУЛАТОВА ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯ ИЯЛӘРЕ



Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институты инициативасы белән алтынчы ел инде шагыйрә Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Клара Булатова исемендәге премия тапшыру тантанасы уздырылда. 17 нче мартта узган тантанада шагыйрә Клара Булатова үзе, Әлмәт Язучылар оешмасы вәкилләре катнашты.

Конкурс гомуми урта белем бирү мәктәпләре, лицей, гимназия укучылары, югары уку йортлары студентлар арасында уздырылды. Катнашучылар “Әдәби иҗат” һәм “Фәнни эш” юнәлешләре буенча көч сынашты. Конкурс әдәби-иҗат процессын стимуллаштыру, яшь буынның рухи һәм әхлакый үсешенә йогынты ясау, шулай ук Клара Булатова иҗатын пропагандалау максатыннан оештырылган.

Клара Булатованың Туган як гимнына әверелгән “Шушы яктан, шушы туфрактан без” дип аталган җыры белән башланып киткән тантанада шагыйрә үзе чыгыш ясады, аның шигырьләре яңгырады, иҗатына багышланган фәнни эшләр, яшь каләм тибрәтүчеләрнең иҗади эшләре тыңланды.

Әлеге конкурста Мөслим районы мәктәпләрендә укучы егетләр һәм кызлар бик теләп катнаштылар.

Мөслим гимназиясе I дәрәҗә Диплом һәм премия белән бүләкләнде. “Былбыл” иҗат берләшмәсе җитәкчесе Тимергалиева Э.В. конкурска 6 ел рәттән җиңүчеләр әзерләгән өчен Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

Шәхси нәтиҗәләргә килгәндә, Мөслим гимназиясенең 8б сыйныфы укучысы Алинә Хәертдинова һәм 6б сыйныфы укучысы Диләрә Нуриева “Әдәби иҗат” номинациясендә III дәрәҗә Диплом һәм премияләргә ия булдылар (фәнни җитәкчеләре З.Н.Шәнгәрәева, Э.В.Тимергалиева). Мөслим гимназиясе укучылары Илүзә Кашапова, Шамил Миннегалиев, Лиана Хәбибуллина, Алия Солтанова конкурсның лауреатлары булды. Катнашучы диплом һәм бүләк ияләре: Зөлфәт Әхмәтҗанов, Сөмбел Галиева, Зәһрә Закирова, Айзат Шәмсетдинов, Сабина Идиатуллина, Айзирәк Исламова, Шәһрәт Мирзамуратов, И.Хафизова, А.Зарипов, И.Харисов (укытучылары Г.Ш.Мирзасалихова, М.А.Идиатуллина, Г.М.Солтанова, Г.Ф.Исмәгыйлова, З.З.Авзалова, Г.М.Мирзамуратова).

Тантанада чыгыш ясаучылар Мөслим гимназиясе укучыларның иҗатка тартылуын матур күренеш дип бәяләделәр.

***Педагог-китапханәче Гөлшат Солтанова***

## “ИЛҺАМ” БӘЙГЕСЕ ҖИҢҮЛӘРГӘ РУХЛАНДЫРА



Республикакүләм “Илһам” бәйгесенең икенче туры Яр Чаллы шәһәрендә үтте. “Журналистика” номинациясендә гимназиянең 9а сыйныфы укучысы Гыйздәтов Динар һәм 10а сыйныфы укучысы Илүзә Кашапова үз эшләрен якладылар. Алар 21 апрельдә Баскетхоллда узачак “Туган тел” форумы кысаларында бүләкләнү тантанасына чакыру алдылар.

Илүзә “Илһам” бәйгесендә дүртенче ел рәттән катнаша. “Проза” номинациясендә 1 -3 урыннар яулаган кыз быел үзен “Журналистка” номинациясендә сынап карый. “ТЫЛСЫМ+” газетасы журналисты булардак язмалары аша сез аны таныйсыз. Динар иҗади бәйгеләрдә беренче тапкыр катнаша. Укучыларыбызга уңышлар телибез.

## УКУЧЫЛАР ИҖАТЫ

### ГОМЕРЛЕК САБАК
### (хикәя)

Кечкенә чагымнан ук хәтеремә уелып калган бер вакыйга еш исемә төшә. Ул миңа – гомерлек сабак булды.

Дәү әниебез яшәгән йорт янындагы бакчада төрле җимеш агачларыннан тыш, сары, кара, ак, кызыл карлыган куаклары да бар. Җәйге чорда карлыганнарның ботаклары сырганак кебек, җимешләрдән сыгылып тора. Бигрәк тә, ак, кызыл тәстәгеләре күзләрне камаштыра. Үзебез генә түгел, килгән-киткән туганнар да, дус-ишләр дә, күрше-күләннәр дә бу кызыктыргыч, тәмле җимешләрне авыз итмичә калмый. Күрше тавыгы күркә булып күренә дигәндәй, кеше бакчасында үскәне тәмлерәк тә тоела торгандыр инде аның. Күзләрне кызыктырырдай әлеге җимешләргә читтән генә кызыгып, көнләшеп йөрүчеләр дә булган, күрәсең.

Бервакыт иртән торып, урамга чыксам, капка янында сындырып ташланган карлыган ботакларын күреп, тынсыз калдым. Әле кичә генә янып утырган ак, кызыл җимешләр җиргә коелып изелгән, бернәрсәгә яраксыз чүп булып, бакчаларны ямьсезләп яталар. Карлыганнарыма күз ташладым. Моңа кадәр үз матурлыкларына масаеп, горур кыяфәттә утырган куаклар шәрәләнеп, бөрешеп калган. Башлары түбән иелгән. Бик тә кызгандым үзләрен. Шулчак апам да, татлы йокысыннан уянып, бакчага чыкты. Сындырылган, мәсхәрәләнгән куакларны, җирдә аунап яткан аклы, кызыллы җимешле тәлгәшләрне күреп, күңеле сыкрады. "Оятсызлар... Ничек куллары күтәрелде икән?" - диде ул, еламсырап.

Ямьсез булып күренеп тормасын өчен, куаклардагы яртылаш сынган ботакларны төбеннән үк кисеп алдык. Урам якта чәчелеп ятканнарын да җыеп алырга дип чыккан идек, яныбызга өне-тыны бетеп, Зариф белән Гариф килеп җиттеләр.

– Кызлар, зинһар, ачуланмагыз... Әби белән бабай "биетте" генә безне... Менә бу "чыбыклар" арт санга ару гына төштеләр... – диде Зариф, еламсырап, кулындагы карлыган ботакларына ишарәләп.

– Без бит үзебез генә түгел идек... Өч-дүрт малай бергәләп кызыгып өзгән идек карлыганнарны... Әби әйтә, кеше әйберсенә рөхсәтсез тияргә ярамый, кулыгыз корыр, ди... Дәү әниегездән гафу үтенергә килдек... – диде Гариф, күз яшьләрен сөртә-сөртә.



Ишегалдында тавык -чебеш ашатып йөргән дәү әниебез үзара сөйләшкәнебезне ишетеп торган, күрәсең, безне үзе янына дәште. Кулыбыздагы сынык ботакларны аңардан яшермәкче булдык.

– Балакайлар, бөтенегез дә янныма килегез әле, - диде ул, ягымлы гына итеп. Шултикле сабырлык белән матур итеп чакыргач, ничек инде аның янына килмисең, ди?! Ялтыравыклы кәгазьләргә төрелгән тәмле конфет бирергә җыенганмени?! Болан җитезлегедәй йөгереп килеп бастык дәү әниебезнең каршысына. Бер мизгелгә ни булганын да аңлашмыйча калдык: йөгерек кәлтә тизлегедәй ул апамның да, минем дә, Зариф белән Гарифның да баш түбәсеннән бер чеметеп чәчебезне тарткалады. Кыр куяннары кебек, үрле-кырлы сикердек. Апамның, минем генә түгел, янәшәмдәге "каракларның"да күзләреннән мөлдерәп яшьләр тамды. "Әзелеп яраткан, хөрмәт иткән дәү әниебез бик тә усал икән..." – дип уйларга да өлгермәдем, ул исә, берни булмагандай тагын да тәмлерәк тел белән сөйләп, томаланган ми күзәнәкләребезне уятты.

– Балакайларым, сез бит инде хәзер зур үскән кызлар, акыллы малайлар... Әйткәннәремне колагыгызга чорнап куегыз, баш миләрегезгә сеңдерегез... Беркайчан да рөхсәтсез кеше әйберенә кул сузмагыз, агач, куак ботакларын сындырмагыз... Барча үсемлекләрнең дә җаны, тере күзәнәкләре бар. Ботакларын, сабакларын сындыргач, алар кибәләр, шиңәләр, корыйлар... Балакайларым, башыгыз, чәч төпләрегез авырттымы? Аңлыйм хәлегезне... Менә шулай ботарланган, йолкынган агач-куаклар да сызланалар... Шуны онытмагыз, кылынган начар гамәлләр өчен "тегe дөньялыкта" башыгыздан бар чәчегезне дә шулай берәмтекләп йолкырлар...

Бу сүзләрне ишеткәч, бөтенебез дә шүрләп, сагаеп калдык. Зариф белән Гариф дәү әниебездән гафу үтенделәр. Әй, үкенделәр дә соң ахырын уйламыйча ялгыш гамәл кылганнары өчен.

Дәү әниемне педагогия институтын, академия тәмамлаган белгеч, тәрбияче икән дип уйлый күрмәгез тагын. Аның бөтен тәрбиясе – җанының эретерлек үтемле сүзләрендә һәм сөяләнеп беткән җитез кулларында! Әнә шул чактагы гыйбрәтле вакыйганы һичкайчан онытасым юк. Берәрсе агачтан яфрак кына өзсә дә, тетрәнеп куям, йөрәгем сукылдый. "И-их, җәзасыз калмас, "тегe дөньялыкта" интегәчәк икән бу бәндә..." – дип, андыйларны кызганам. Үсә төшкән саен, дәү әниемә карата хөрмәтем, рәхмәт хисләрем арткан-арта бара. Әгәр дә сине ярамаган эш өстендә, ниндидер юньсезлек, әтлек юлында тотсалар, әти-әниеңнең, әби-бабаңның сине күреп, әләктереп алып, колагыңны борырга, яисә арт ягыңа чыбык белән сыдырырга хакы бардыр. Ул, гомерлек сабак булып, кешене гомере буена озата барачак.

***Хәертдинова Алинә,***
***8 нче б сыйныф укучысы***



## ИҖАДИ СӘХИФӘ



### ТЫНЫЧЛЫК ТЕЛИМ

Зәңгәр күктә – ак болытлар,
Уйный кояш нурлары.
Алтын бодай башаклары
Дулкынлата кырларны.

Сокланабыз гүзәллеккә,
Барыбыз бер фикердә:
Тилмермәсен кеше ачка,
Сугыш булмасын җирдә.

Кара кайгы – сугыш җиле
Кермәсен илебезгә.
Аяк чалмасын бомбалар
Киләчәк кенебезгә!

### КҮК ЙӨЗЕНДӘ АЛТЫН УРАК

Туган җирем, сабый бала кебек,
Изрәп йоклый, татлы төш күреп.
Төн уртасы. Тик тынгысыз әтәч
Сөрән салды, төшне бүлдереп.

Зәңгәр күк йөзендә алтын урак
Гизеп йөри йолдыз басуын...
Төн пәрдәсен ачты алсу нурлар,
Хәбәр итеп таңның атуын.

### МИНЕМ ПЕСИ

Минем песи бик шаян,
Уйнарга бик ярата.
Әниемнең җеп йомгагын
Тарата да тарата.

Тәпие белән уйнатып,
Өстәл астына кертә.
- Куй урыныңа! - дисәң дә.
Һаман суккалап йөртә.

Мин мәктәпкә киткән чакта
Тәрәзәдән карап кала.
Әйләнеп кайткан чагында
Ишектән каршы ала.

***Солтанова Алия,***
***5 нче б сыйныфы укучысы***

### ИНТЕРНЕТ-БАЛАЛАР

Хәзер шундый замана –
Ул чир бар һәр балада.
Ата-анага – "ай-һай!",
Ә балаларга – Wi-Fi.

Әби-бабай әйрәтә:
- Син, кызым, укы китап!
Ә мин аны ишетмим,
Миңа кирәк тик Wi-Fi.

- Чапма, тавышланма,- дисәң,
Мине туктатып булмый.
Каршыма компьютер куйсаң,
Инде торгызып булмый.

Бу чир туа һәркемдә,
Борчылмасын беркем дә.
Кайгырмагыз, әниләр:
Без – Итернет-бәбиләр!

### ПЕСИЛӘРЕМ

Анасы бар, атасы бар,
Абыйсы, бар апасы.
Берсе дә тик тормый торган
Алты-җиде баласы.

Песиләрем бигрәк матур,
Мамык кебек йомшаклар.
Җиде төсле тун кигәннәр,
Ай-яй матур йомгаклар!

Бигрәкләр дә шаяннар шул -
Яратам мин аларны.
Әгәр дә яшереп куйсам,
Аналары табармы?

### УЕН

Беркөнне без әбидә
Рәхәтләнеп уйнадык.
Ниләр генә кылмадык –
Уен уйнап туймадык.

Шалашлар да ясадык,
Театр да куйдык без.
Бу уеннарның тәмен
Аңламассыз инде сез.

Диңгездәге корабка
Өстәлебез әйләнде...
Биш минутта өебезнең
Асты өскә әйләнде.

Уенның иң кызган чагы –
Әби керде. Шаккатты.
Апайларым ул арада
Шкаф артына качты.

Пиратлар һөҗүм иткәнен
Әби карый таң калып.
Ике күзен кысып алды,
Чыгып китте нык басып.

...Инде мәнә кич җитте,
Уен уйнап ардык без.
Хәзер бу баррикаданы
Ничек җыештырырбыз?

### АПА БУЛГАЧ

Унбер яшьтә генә үзем,
Мин күптән инде апа.
Энеләрем, сеңелләрем
Мине бик тә ярата.

Шаулашалар, и уйныйлар,
Тиктормас шул үзләре.
Аларны карап йөреп гел,
Арыйм кайбер көннәрне.

Мин дә шулай булганмынмы -
Уйлар килә башыма.
Ниләр кылганмындыр, дим,
Әнем, сеңлем яшендә?

Апа булгач, апа инде –
Кечкенәләрне карыйм.
Алар үсә алма кебек,
Мин генә менә арыйм...

***Лиана Хәбибуллина,***
***6 нчы б сыйныфы укучысы***

### ҮЗЕМ ТУРЫНДА ҮЗЕМ

Кечкенәдән шук булсам да,
Мин әйбәт малай идем.
Күңелгә килгән уйларны
Гамәлгә сала идем.

Бер дә ялкау түгелмен,
Бик тырыш үзем.
Әтием гел мактап тора:
Син бит уң кулым!

Спорт белән шөгыльләнәм,
Тимераякта шуам.
Чаңгыда да җилдерәм,
Берсе дә калмый миннән.

Әти кебек көчле булам,
Әни кебек биючe.
Миңа карап сөенсеннәр:
Нәсел дәвам итүче!

***Миңнегалиев Шамил,***
***7 нче в сыйныфы укучысы***

## БЕЗ — ТУКАЙ ОНЫКЛАРЫ

### ЯЗ

Килеп җитте, ниһаять,
Сагынып көткән безнең яз.
Тышта уйнавы рәхәт
Күкләребез чалт аяз.

Тиздән күмелер табигать
Ямь-яшел матур төскә.
Сулар агар, кар эреп
Көннәр җылынып төсле.

Кайтып туган оясына
Өзелеп сайрар сыерчык.
Оясы да көтеп тора
Көзен киткән бу кошчык.

***Хөсәенова Алинә,
2 нче а сыйныфы
укучысы***

### БӘХЕТ АГАЧЫ

Бәхет агачы ясадык
Әнием белән бергә.
Тәңкә саен теләкләр
Теләдек һәммәбез дә.

Иң кирәге –сәламәтлек,
Сәламәт булсын һәркем.
Авырмыйм, чирләмим, дип
Зарядка ясыйм һәр көн.

Әйтерсең лә, чын агач,
Исем китте ясагач.
Яфраклары да чын бәрхет
Теләп торсын ул бәхет.

***Әюпова Илнара, 1 нче а
сыйныфы укучысы***

### БЕР ЕЛАК

Җылы язлар килеп җитте,
Көннәр һаман яктыра.
Ә безнең ишегалдында
Кемдер елап утыра.

Күз яшьләре урам тулы,
Әмма кая агалар?
Ә янында көлә-көлә,
Уйный бала-чагалар.

Елаучының исемен дә
Әйтеп биримме, дуслар?
Яз көнендә кем еласын -
Елый бары соңгы кар!

***Галимҗанова Айсылу,
2 нче а сыйныф
укучысы***



### ТЫРЫШ УКУЧЫ

Уку миңа авыр түгел
Кил, сине дә өйрәтәм.
«2»лене «3»кә кушып
«5»леләргә төзәтәм…

Көндәлектә кызыл белән
Тезелешкән билгеләр.
Аңлый алмыйм:
Әти-әни
Нигә һаман тиргиләр?!

### КЫШ

Иртән торсам, тәрәзәне
Бизәп киткән Кыш Бабай.
Урамны да күрә алмыйм,
Шаярма инде алай!

Мәктәпкә барыр алдыннан
Күз салам тәрәзәгә.
Кыш буе шулай шаярсаң
Ничек сиңа түзәргә!?

***Мингазова Ралина, 3 нче
б сыйныфы укучысы***

### ТАБИГАТЬ БАЛАСЫ

Без - табигать балалары
Табигатьне сөябез.
Матур гөлләр үстерәбез,
Көн дә сулар сибәбез.

Җәйләр җитсә, табигатькә
Ял итәргә чыгабыз.
Артыбыздан чүп
калдырмый
Җыештырып китәбез.

***Гатауллина Ильвина,
1 нче б сыйныфы
укучысы***

### ҖӘЙ КӨНЕНДӘ

Әй рәхәт, җәй көнендә
Ык буенда коену.
Яр буенда талларының
Куенына сыену.

Туган якның гүзәллеген
Дуслар, бергәләп саклыйк,
Табигать ул - һәр кешегә
Көч биргәнен онытмыйк.

***Зарипова Азалия,
1 нче б сыйныфы
укучысы***

### ТЕЛЕВИЗОР КАРШЫНДА

Әни карый гимнастика,
Мин яратам баскетбол.
Әти хоккейны үз итә,
Энем карый бадминтон.

***Әхмәтҗанов Зөлфәт,
3 нче б сыйныфы
укучысы***

## 2017 НЧЕ ЕЛ — РОССИЯДӘ ЭКОЛОГИЯ ЕЛЫ

### УТ ЧӘЧӘК (ӘКИЯТ)



Борын-борын заманда яшәгән, ди, киң болында кып-кызыл матур чәчәк. Аны тирә-яктагы чәчәкләр, үләннәр “Ут чәчәк” дип атаганнар, ди. Чөнки ул төнлә дә хайваннарга юл күрсәтеп янып утырган. Ут чәчәк иртән иртүк кояш белән уянып, таң чыклары белән юына икән. Аның матурлыгына тирә-яктагы үсемлекләр таң калган, хәтта хайваннар да аның ягыннан узганда читләп кенә, басмаска тырышып узалар икән, ди. Менә бервакыт көчле җил чыккан, җирдә яткан кәгазь, полиэтиленнар оча башлаган, шул вакытта кара төстәге полиэтилин очып килгән дә, Ут чәчәккә эләгеп калган. Ут чәчәк ярдәм сорап, алга, артка борылган, кычкырып та караган, ләкин аны берәү дә күрмәгән, ишетмәгән. Сулыш алырга авыр була башлаган, һава җитмәгән. Ут чәчәк әкренләп сула, шиңә башлаган, бик тә талчыккан, җылы шифалы яңгыр суларының тавышын гына ишетеп торган Ут чәчәк. Шулай итеп, Ут чәчәк сыгылып төшкән һәм үсүдән дә туктаган. Аның урынында кара җир генә калган, ди.

Менә дусларым, кешеләрнең мәрхәмәтсез, тәртипсезлеге аркасында кешеләр үзләре генә түгел, үсемлекләр, хайваннар да интегә икән. Ял итәргә кырга, урманнарга баргач, әниләрегезгә, әтиләрегезгә, иптәшләрегезгә әйтегез, полиэтилен капчыкларны, капрон шешәләрне, консерв, сок савытларын ташламасыннар. Аларны махсус чүп савытларына салыгыз!

Шуны онытмыйк: табигатьне саклыйк - үзебезне яклыйк!

***Зарипова Азалия, 1 нче б сыйныфы укучысы***



Б Е З Н Е Ң Р Е К Л А М А

### КВЕСТ-УЕН



*26 апрельдә Мөслим гимназиясе базасында Габдулла Тукай туган көнгә багышланган әдәби-музыкаль, информацион-лингвистик квест-уен үткәрелә. Ул Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы башкарма комитеты планы нигезендә һәм «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыру максатыннан үткәрелә.*

*Квест-уенда гомуми белем оешмаларының VIII–XI сыйныф укучылары катнаша ала. Команда составы: 3 кыз, 3 егет. Укучыларның рус, татар, инглиз телен камил белүе, Габдулла Тукайның яңартылган сайты http://gabdullatukay.ru/ материаллары белән таныш булуы шарт булып тора. Актаныш һәм Башкортстан Республикасының Илеш районнары, Мөслим районының барлык урта мәктәпләреннән 8 команда катнашуы көтелә. Фойеда Г.Тукай иҗаты буенча күргәзмә урнаштырылачак. Чараны оештыруда гимназиянең үзидарә советы булышлык итәчәк. Сезне Г.Тукай туган көнгә багышланган чараларда көтеп калабыз.*

*Нигезләмә белән гимназия сайтында танышырга мөмкин https://edu.tatar.ru/muslum/sch2/muslumgym.*

## ГИМНАЗИЯ УКУЧЫЛАРЫ - “БЕЗ БЕРГӘ” РОССИЯКҮЛӘМ АКЦИЯСЕНДӘ







## ГИМНАЗИЯНЕҢ СПОРТ ТОРМЫШЫ

ГТО



ПРЕЗИДЕНТ УЕННАРЫ



ЙӨЗҮ



ТЫЛСЫМ+
Март-апрель, 2017 нче ел
**Мөслим гимназиясе укучылары газетасы**

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректорлар:** Шамукаева Эльвина
Солтанова Эльвина
**Корреспондентлар:** Сәфәргалина Инзилә
Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Галиев Илназ
**Компьютерда җыючылар:**
Гилемов Азат
**Гамәлгә куючы:**
Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/sch2/muslumgym